КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 сентябрь г.Казань № 942

2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен расларга.

2. Бу карарның 1 пунктында расланган социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре барлык милек рәвешләрендәге һәм ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмаларында эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары, урта звено белгечләре әзерләү программалары, бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча белем ала торган укучыларга кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга дәүләт һөнә-ри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешма-ларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2021 ел, 15 сентябрь, 873 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 942 нче
карары белән расланды

2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр исеме | Түбәндәге программалар буенча белем алучыларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләме, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү | төп гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү | урта гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү | урта звено белгечләрен әзерләү | бакалавриат, специалитет, магистратура |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Белем бирү оешмасын тәмамлаганда ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга | 899 | 899 | 899 | 899 | 899 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга бер тапкыр бирелә торган пособие | | | | | |
| 2. | Белем бирү оешмасын тәмамлаганда ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 |
| 3. | Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасын- | - | 3 210 | 3 210 | 3 210 | 8 303 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | дагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу өчен кирәк-яраклар сатып алуга ел саен бирелә торган пособие | | | | | |
| 4. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен ел саен бирелә торган пособие | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 |
| 5. | 2023 елның 1 сентябренә кадәр ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасында- | - | 1 046 | 1 046 | 1 046 | 1 046 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | гы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен бирелә торган стипендия | | | | | |
| 6. | 2023 елның 1 сентябреннән ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен бирелә торган стипендия | - | 1 110 | 1 110 | 1 110 | 1 110 |
| 7. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки | 7 877 | 7 877 | 9 076 | 9 076 | 9 076 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | берсен генә югалткан затларга туклану өчен ай саен бирелә торган пособие | | | | | |